**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Кызыл Юл поселогы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«11» апрель 2024 ел № 10

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Кызыл Юл поселогы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлегенең Кызыл Юл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 15.11.2023 ел, № 4 номерлы карарның аны түбәндәге редакциядә бәян итеп 1 пунктына үзгәрешләр кертергә:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Кызыл Юл поселогында яшәүче, 1 гр инвалидтан тыш, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Кызыл Юл торак пунктында янгынга каршы гидрант сатып алу һәм урнаштыру).

Халык җыенында рәислек итүче: Ә.Ф. Сафиуллина

Әмзә авыл җирлеге башлыгы Ә.Ф.Сафиуллина